Татарстан Республикасы
Кукмара муниципаль районы
Түбән Өскебаш авыл җирлеге Советы

01 октябрь 2020 ел №5

КАРАР

«Түбән Өскебаш авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирле үзидарә органнары һәм «Кукмара муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең җирле үзидарә органнары арасында җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча вәкаләтләрнең бер өлешен тапшыру турында килешүләр төзү Тәртибен раслау хакында»

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясындагы 4 өлеше нигезендә Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Түбән Өскебаш авыл җирлеге Советы карар бирде:

Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы «Түбән Өскебаш авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирле үзидарә органнары һәм Татарстан Республикасы «Кукмара муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең җирле үзидарә органнары арасында җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча вәкаләтләрнең бер өлешен тапшыру турында килешүләр төзүнең кушымта Тәртибен расларга

Түбән Өскебаш
авыл җирлеге башлыгы: ________________ Н.М.Мөхәммәтҗанов

Кукмара муниципаль районы Түбән Өскебаш авыл жирлеге Советы карары белән расланды
01.10.2020 ел №5

Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы «Түбән Өскебаш авыл жирлеге» муниципаль берәмлегенең жирле үзидарә органнары һәм Татарстан Республикасы «Кукмара муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең жирле үзидарә органнары арасында жирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча вәкаләтләрнең бер өлешен тапшыру турында килешүләр төзү Тәртибе

1. Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының «Түбән Өскебаш авыл жирлеге» муниципаль берәмлегенең жирле үзидарә органнары (алга таба – авыл жирлеге) һәм Татарстан Республикасы «Кукмара муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең жирле үзидарә органнары (алга таба – Район) арасында жирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча вәкаләтләр өлешен тапшыру турында килешүләр төзүнең әлеге Тәртибе «Россия Федерациясендә жирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – «Россия Федерациясендә жирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль закон) нигезендә эшләнде.

2. Жирлекнең жирле үзидарә органнары Россия Федерациясе Бюджет кодексы нигезендә Жирлек бюджетыннан бирелә торган бюджетара трансфертлар исәбенә жирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча үз вәкаләтләренең бер өлешен гамәлгә ашыруны тапшыру турында Район жирле үзидарә органнары белән килешүләр төзергә хокуклы.

Шул ук вакытта Районның жирле үзидарә органнары «Россия Федерациясендә жирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль закон, Район жирле үзидарә органнарына Жирлекнең жирле әһәмияттәге мәсьәләләрен хәл итү буенча аерым вәкаләтләрне тапшыру турындагы килешүләр нигезендә Жирлек территориясендә авыл жирлегенең жирле әһәмияттәге мәсьәләләрен хәл итү буенча вәкаләтләрне гамәлгә ашыралар.

3. Жирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча вәкаләтләрнең бер өлешен жирлек һәм районның жирле үзидарә органнары тапшыра ала.

4. Авыл жирлеге муниципаль берәмлеге башкарма комитеты үз инициативасы белән яисә Район жирле үзидарә органнары инициативасын карап, аны алганнан соң 30 көн эчендә жирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча аерым вәкаләтләрне тапшыру турында Жирлек Советы карары проектын әзерли.

5. Авыл жирлеге муниципаль берәмлеге башкарма комитеты вәкаләтләрнең бер өлешен тапшыру турындагы Жирлек Советы карары проектын Жирлек Советына норматив хокукый актлар керткәндә билгеләнгән тәртиптә һәм срокларда кертә.

6. Жирлек Советы Жирлекнең жирле әһәмияттәге мәсьәләләрен хәл итү буенча вәкаләтләрнең бер өлешен Район жирле үзидарә органнарына тапшыру турында карар кабул итә һәм кабул ителгән карарны Район жирле үзидарә органнарына карауга жибәрә.

7. Район Советы Авыл жирлеге Советы карарын карау буенча уңай нәтиҗәгә килгәч, Җирлек жирле үзидарә органнары һәм Районның жирле үзидарә органнары арасында килешү төзелә.

Күрсәтелгән килешү билгеле бер вакытка төзелергә, аның гамәлдә булуын туктату, шул исәптән вакытыннан алда туктату нигезләрен һәм тәртибен билгели торган нигезләмәне, тапшырыла торган вәкаләтләрне гамәлгә ашыру өчен кирәкле бюджетара трансфертларның әлеге өлешендә күрсәтелгән еллык күләмен билгеләү тәртибе нигезләмәсен, шулай ук килешүләрне үтәмәгән өчен финанс санкцияләрен күздә тотарга тиеш.

Килешү проектын эшләү өчен, һәр яктан тигез санда вәкилләр кертеп, эшче төркем төзелергә мөмкин. Эшче төркем үз эше нәтиҗәләре буенча килешү якларының мәнфәгатьләрен максималь рәвештә исәпкә ала торган килешү проектын әзерли.

8. Әгәр Жирлек Советы Җирлекнең җирле әһәмияттәге мәсьәләләрен хәл итү буенча вәкаләтләрнең бер өлешен Районның инициатива жибәргән жирле үзидарә органнарына тапшыру турында карар проектын кире каккан очракта, алар инициативасын карау нәтиҗәләре турында хат жибәрелә.

9. Килешүдә каралган вәкаләтләрне үтәү өчен кирәкле финанс чаралары бюджетара трансфертлар рәвешендә бирелә.

Бюджетара трансфертлардан максатчан файдаланмаган очракта, алар Жирлек бюджетына ун көн эчендә кире кайтарылырга тиеш.

Тапшырыла торган вәкаләтләрне гамәлгә ашыру өчен кирәкле бюджетара трансфертларны тапшыру максатларында, бюджет законнары нигезендә, тапшырылган вәкаләтләрне тормышка ашыру өчен кирәкле акчалар карала торган район һәм жирлек бюджеты турындагы карарларга үзгәрешләр кертелә.

Тапшырылган вәкаләтләрне гамәлгә ашыру өчен Жирлек бюджетыннан бирелә торган бюджетара трансфертларны формалаштыру, күчерү һәм исәпкә алу Россия Федерациясе Бюджет законнары нигезендә гамәлгә ашырыла.

Вәкаләтләрнең бер өлешен гамәлгә ашыру өчен бирелә торган финанс чаралары ай саен тигез өлешләрдә күчерелә, әмма финанс чараларының барлык суммасын бер үк вакытта күчерү дә мөмкин.

10. Вәкаләтләрнең бер өлешен гамәлгә ашыру өчен кирәк булган очракта, түләүсез вакытлы файдалану шартнамәсе нигезендә муниципаль милек тапшырыла.

Түләүсез файдалану шартнамәсе тиз арада төзелә һәм Килешүнең гамәлдә булу вакытына төзелә.

11. Күрсәтелгән килешүләр нигезендә тапшырылган вәкаләтләрне гамәлгә ашыру өчен, Районның жирле үзидарә органнары муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы карарында каралган очракларда һәм тәртиптә үз матди ресурсларыннан һәм финанс чараларыннан файдаланырга хокуклы.

12. Вәкаләтләрен тапшырган Жирлекнең жирле үзидарә органы тапшырылган вәкаләтләрнең үтәлешен тикшерүне гамәлгә ашыра, тапшырылган финанс чараларыннан һәм матди ресурслардан файдалану турында кирәкле мәгълүматны сората.

13. Килешүнең гамәлдә булуы вакытыннан алда туктатылырга мөмкин:

- Яклар килешүе буенча;

- берьяклы тәртиптә, бер Як үз йөкләмәләрен үтәмәгән яки тиешенчә үтәмәгән очракта.

14. Килешүнең гамәлдә булуы вакытыннан алда туктатылган очракта, тапшырылган вәкаләтләрне гамәлгә ашыручы Район жирле үзидарә органы файдаланылмаган финанс чараларын, матди ресурсларны һәм вәкаләтләрне гамәлгә ашыру өчен бирелгән мөлкәтне кире кайтара.

15. Килешүне гамәлгә ашыру белән бәйле бәхәсләр сөйләшүләр һәм башка килештерү процедуралары юлы белән хәл ителә. Бәхәсне сөйләшүләр яки килештерү процедуралары үткәрү юлы белән хәл итү мөмкин булмаган очракта, ул законнарда каралган башка тәртиптә каралырга тиеш.